ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 август 2021ел № 5205

Башкарма комитетның 2009 елның 8 апрелендәге 1357 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә кайнатылмаган, аертылмаган сөтне агызып сату урыннары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 статьясындагы 11 өлешнең 4 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Кайнатылмаган, аертылмаган сөт сату турында» 2009 елның 8 апрелендәге 1357 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 16 февралендәге 1040 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә кайнатылмаган, аертылмаган сөтне агызып сату урыннары исемлегенә, түбәндәге эчтәлектә 20 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | |
|---|---|
| 20. | ЗЯБ поселогы, Комаров урамы буенча 15/1 һәм 15/19 торак йортлар арасындагы мәйданчыкта |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов